| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.09.2018 г.Казань № 860

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 15 октяберендә теркәлде № 4928

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының « Торак бинага һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак бинага һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак бинага һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 31.10.2016 № 612, 08.06.2017 № 349, 01.06.2018 № 426 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак бинага һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, 3 пункт нигезләмәләреннән тыш, алары өчен гамәлгә керүендә бүтән срок билгеләнгән.

3. Әлеге боерык белән расланган Үзгәрешләрнең җитмеш алтынчы-җитмеш тугызынчы, сиксән өченче-сиксән алтынчы, туксанынчы-туксан икенче абзацлары 2018 елның 18 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.09.2018 №860 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Үзәк бүлекләре урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:»;

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.5.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru;).»

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 14, 1257 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 34, 3374 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр бирү турында» 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары белән расланган Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр бирү кагыйдәләре (алга таба – 761 номерлы кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 51, 5547 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Торак бинага һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидияләр бирүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрен куллану буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 30 декабрендәге 1037/пр номерлы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 857 номерлы боерыгы (алга таба – Методик күрсәтмәләр);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә һәм айлык акчалата түләүләр түләүгә субсидияләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 5, 0156 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләгәндә халыкка социаль ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2005 елның 29 декабрендәге 665 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләгәндә халыкка социаль ярдәм итүнең өстәмә чараларын бирү турында нигезләмә (алга таба – 665 номерлы нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2006, № 5, 0129 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

1.7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы)»;»;

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында:

2.1 пунктта «738 номерлы нигезләмәнең 1.2 п.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктта «738 номерлы нигезләмәнең 1.4 п.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Регламетның 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада барлык гаилә әгъзаларын һәм туганлык дәрәҗәсен күрсәтеп, гариза.

2. Мөрәҗәгать итүченең аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән торак урынга хуҗа булуының һәм аннан файдалануының хокукый нигезләрен раслаучы документларның күчермәләре, андыйларга түбәндәге документларның берсе карый:

а) хосусый торак фондында найм шартнамәсе буенча торак урын яллаучыга – торак урынның найм шартнамәсе;

б) торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яки торак йортның бер өлешенә) хокуклары Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуның бердәм реестрында теркәлмәгән милекче өчен:

торак яки торак-төзелеш кооперативыннан кооператив әгъзасы булып торган мөрәҗәгать итүченең кооперативтан әлеге затка тапшырылган фатирга пай

кертеменең тулысынча түләнгән булуы турында кооперативның вәкаләтле идарә органыннан аның уставта билгеләнгән компетенциясе нигезендә бирелгән белешмә;

«Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында» федераль закон үз көченә кергән вакытка кадәр торак урынга милекчелек хокукы барлыкка килүен раслаучы документ;

торак урынга милекчелек хокукына карата законлы көченә кергән суд акты (суд карары яки суд билгеләмәсе);

закон яки васыять буенча мирас хокукы турында таныклык;

в) торак яки торак-төзелеш кооперативына карый торган торак урында яшәгән очракта, – торак яки торак-төзелеш кооперативыннан анда мөрәҗәгать итүченең әгъза булып торуы турында кооперативның вәкаләтле идарә органыннан аның уставында билгеләнгән компетенциясенә туры китереп бирелгән белешмә.

3. Мөрәҗәгать итүченең һәм барлык гаилә әгъзаларының субсидия бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслаучы документларның күчермәләре, аларга түбәндәгеләр керә:

төп эш урыныннан һәм барлык өстәмә эш урыннарыннан керемнәр турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан һәм Россия ЭЭМ, Россия Оборона министрлыгыннан гамәлгә ашырыла торган түләүләрдән тыш, барлык дәрәҗә бюджетларыннан, дәүләтнең бюджетка карамаган фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр күләме турында белешмәләр;

милекчелек хокукында мөрәҗәгать итүченеке һәм аның гаилә әгъзаларыныкы булган мөлкәттән керемнәр күләме турында белешмәләрне үз эченә алган документлар (гариза, шартнамә күчермәсе һ.б.);

предметы эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган граждани-хокукый шартнамәләр;

шартнамәләр һәм торак урыннарны поднаемга тапшырудан алынган керемнәр турында белешмәләре булган башка документлар;

салым органы документы белән таныклана торган шәхси эшкуарлар сайлаган салым салу системасына карап, Россия Федерациясенең салым законнарында каралган документлар;

опекада (попечениедә) торган затларны караган өчен опекунга (попечительгә) түләнә торган акчалар күләмен раслаучы документлар;

гражданнарның мөстәкыйль декларацияләнгән керемнәре турында гаризалар, керемнәрне документаль раслау мөмкинлеге булмаганда һәм фактта алынган керемнәр документта күрсәтелгәннән зуррак булган очракта, хезмәт һәм шәхси эшкуарлык эшчәнлегеннән ирекле формада рәсмиләштерелгән керемнәрдән тыш;

шәхси эшкуарның кәгазьдә керемнәрне һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсе, – салымнар һәм җыемнар билгеләүнең гомуми шартлары һәм салым салуның гадиләштерелгән системасы кулланылганда:

шәхси эшкуарның кәгазьдә керемнәрне һәм чыгымнарны һәм хуҗалык операцияләрен исәпкә алу кенәгәсе һәм хисап чорындагы чыгымнарны раслаучы беренчел исәпкә алу документлары, – әгәр салым салу объекты булып чыгымнар зурлыгына киметелмәгән керемнәр торса;

салым органнарында таныкланган салым декларациясе күчермәләре, – эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кулланылган керемнәргә бердәм салым рәвешендәге салым салу системасын кулланганда.

4. Түбәндәгеләрне таныклаучы документларның күчермәләре:

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгына каравын (аталган документлар ведомствоара гарызнамә гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булган очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына);

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе белән торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә чит ил гражданнарына субсидияләр бирүне рөхсәт итә торган халыкара шартнамәсе төзелгән дәүләт гражданлыгына каравын.

Мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында керемнәр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә гражданнарның керемнәре булмавын раслаучы документларның күчермәләрен тапшыра, аларга түбәндәгеләр керә:

а) 23 яшькәчә булган, урта һөнәри белем бирүнең һәм югары белем бирүнең төп мәгариф программалары буенча белем бирү оешмаларында көндезге формада укучы гражданнар өчен, – стипендия булмавы турында белешмә;

б) эшкә урнашмаган гражданнар өчен, – эштән китү турында соңгы язуы булган хезмәт кенәгәләре күчермәләре;

в) гражданнарның эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган яки чикләнгән затлар категорияләренә каравын раслаучы документ, аларга түбәндәгеләр керә:

беренчел тикшерү һәм суд тикшерүе чорында сак астында тотылучы затлар;

дәвамлы стационар дәвалавында булган затлар (шундый дәвалау чорына);

билгеләнгән тәртиптә билгесез югалган яки үлгән дип игълан ителгән чорына кадәр эзләтүдә булган затлар;

3 яшенә җиткәнчегә кадәр бала караучы, 1,5 яшенә җиткәнче баланы карау буенча отпуск чорында ай саен түләнә торган пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган һәм 3 яшенә кадәр бала карау буенча отпускта торучы гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләвен алмаучы аналар.

Дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен белдерүгә үзләренең вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алучы белән даими яшәү урыны буенча яшәүче затларны аның гаилә әгъзалары итеп тану турында суд карары актын тапшырырга хокуклы, – дәүләт хезмәтен алучы белән даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәүче затлар арасында бер гаиләнеке булу мәсьәләсендә аңлашылмаучанлыклар булган очракта.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга яисә заказлы почта юлламасы итеп кулга тапшыру турында белдерү белән җибәрелергә мөмкин.

Гариза белән аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

2.6 пунктта:

2.6 пункттагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешмасы җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

5.2 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү срогы бозылганда;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар,

шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».